| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**


03.08.2022 № 229-П

г. Казань

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2019 елныд 22 октябрендәге «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен раслау турында»гы 126-П санлы боерыгының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2019 елныд 22 октябрендәге «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен раслау турында»гы 126-П санлы боерыгының 1 нче кушымтасына (Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау буенча комитетының 05.10.2020 № 213-П, 05.02.2021 № 24-П, 08.06.2021 № 124-П, 10.02.2022 № 16-П, 09.03.2022 № 31-П боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 24 нче пунктны түбәндәгечә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«24.Казан шәһәре, Кремль урамы, 17/22 йорт адресы буенча урнашкан «Александров пассажы бинасы», 1883 ел, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең картасы (схемасы)




Шартлы билгеләр:

- мәдәни мирас объекты

- мәдәни мирас объекты территориясе

Мәдәни мирас объектының топографик картасы

Казан шәһәре, Кремь урамы, 17/22 йорт адресы буенча урнашкан «Александров пассажы бинасы», 1883 ел, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектын территориясенең чикләре түбәндәгечә уза:

**көньяк-көнбатыш өлеше**: Кремль урамы буенча Муса Җәлил урамы белән кисешкән урынга кадәр, кызыл сызык буенча, җир кишәрлегенең алгы чиге буйлап (4-5 борылыш нокталары);

**төньяк-көнбатыш өлеше**: Муса Җәлил урамы буенча Кремль һәм Дзержинский урамнары белән кисешкән урынга кадәр, кызыл сызык буенча җир кишәрлегенең алгы чиге буйлап (5-6 борылыш нокталары);

**төньяк-көнчыгыш өлеше**: Муса Җәлил урамы буенча Кремль урамы белән кисешкән урынга кадәр, кызыл сызык буенча җир кишәрлегенең алгы чиге буйлап (7-6 борылыш нокталары);

**көньяк-көнчыгыш өлеше**: Кремль урамыннан Дзержинский урамына кадәр, квартал эчендәге чик буйлап (4-3-2-1-10-9-8-7 борылыш нокталары).

Казан шәһәре, Кремь урамы, 17/22 йорт адресы буенча урнашкан «Александров пассажы бинасы», 1883 ел, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **борылыш нокталары таблицасы**

| Нокталарның җирле координаталар системасындагы координаталары (МСК-16) | | | Нокталарның 1984 елгы Бөтендөнья координаталарның геодезик системасындагы координаталары (WGS-84) | |
|---|---|---|---|---|
| **№** | **X** | **Y** | **Төньяк киңлек B** | **Көнчыгыш озынлык L** |
| 1. | 476358,86 | 1305308,33 | 55° 47' 40.37" | 49° 06' 58.75" |
| 2. | 476308,41 | 1305274,42 | 55° 47' 38.74" | 49° 06' 56.80" |
| 3. | 476280,86 | 1305255,46 | 55° 47' 37.85" | 49° 06' 55.71" |
| 4. | 476277,76 | 1305253,37 | 55° 47' 37.75" | 49° 06' 55.59" |
| 5. | 476296,60 | 1305227,04 | 55° 47' 38.36" | 49° 06' 54.08" |
| 6. | 476365,62 | 1305275,05 | 55° 47' 40.59" | 49° 06' 56.84"». |

Комитет рәисе И.Н. Гущин